Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Баграж-Никольский авыл җирлегенең Баграж-Никольский авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

22 ноябрь 2019 ел № 2

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлегенең Баграж-Никольский авылында тавыш бирү нәтиҗәләре турында" гражданнар җыены хисап комиссиясенең 2019 елның 22 ноябрендәге беркетмәсе нигезендә, Татарстан республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлегенең Баграж-Никольский авылында гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлегенең Баграж-Никольский авылында узган халык җыенын үткәрелгән дип танырга, җыенның нәтиҗәләре - дөрес.

2. «Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Баграж-Никольский авыл җирлегенең Баграж-Никольский авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: чүп контейнерлары сатып алу?» мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Альметьевский вестник» газетасында, Баграж-Никольский авылы, Үзәк урам, 31б йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында бастырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

Халык җыенында рәислек итүче: П.Н. Чукашов